Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советының икенче утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

31 октябрь, 2025 ел № 6

Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җыеннарны билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге уставының 23 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 109 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 34 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыеннарны түбәндәге торак пунктларда билгеләргә:

1.1. Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Ленино-Кокушкино авылының Казан, Кояшлы урамнары гражданнары җыенын 2025 елның 17 ноябрендә Кояшлы урамы 4 нче номерлы йорт янында 16.00 сәгатьтә үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2026 елда Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Ленино-Кокушкино авылы Казан, Кояшлы урамнары гражданнары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 7500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә

ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кояшлы ур.)

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Ленино-Кокушкино авылының Бэхетле, Луговая, Овражная урамнары гражданнары җыенын 2025 елның 25 ноябрендә Бэхетле урамы 3 нче номерлы йорт янында 12.00 сәгатьтә үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2026 елда Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Ленино-Кокушкино авылы Бэхетле, Луговая, Овражная урамнары гражданнары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 12500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Бэхетле ур.)

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Олы Бутырка авылында Киров урамындагы гражданнар җыенын 2025 елның 21 ноябрендә 16.00 сәгатьтә «Бабушкин» шәхси эшмәкәрлек предприятиесе кибете янында уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Олы Бутырка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Киров ур.)

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р. Сәйфетдинов